МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.05.2019 Казан ш. № 211-пр

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтнең билгеләнгәнчә файдаланылуын һәм сакланышын контрольдә тотуны оештыру тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге № 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсе нигезендә, дәүләт мөлкәте белән нәтиҗәле идарә итүне тәэмин итү һәм аннан файдалануны контрольдә тотуны көчәйтү максатларында боерам:

1. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтнең билгеләнгәнчә файдаланылуын һәм сакланышын контрольдә тотуны оештыруның тәкъдим ителгән тәртибен расларга.
2. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтнең, шул исәптән, җир кишәрлекләренең, нәтиҗәле файдаланылуын һәм сакланышын тикшерү үткәрү буенча эшче төркемдә катнашучыларга расланган Тәртипкә таянып эш итәргә.
3. «Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтнең билгеләнгәнчә файдаланылуын һәм сакланышын контрольдә тотуны оештыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 22.05.2013 № 1476-р карарын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
16.05.2019 № 211-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы
милкендә булган мөлкәтнең билгеләнгәнчә файдаланылуын һәм саклануын
контрольдә тотуны оештыру
тәртибе

1. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтнең билгеләнгәнчә файдаланылуын һәм саклануын контрольдә тотуны оештыру тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясенең Гражданлык кодексына, Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турында кодексына, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге № 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсе нигезендә әзерләнгән.

2. Тәртип Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (алга таба – Министрлык) структур бүлекчәләренең торак фонды объектларыннан тыш Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтнең, шул исәптән, җир кишәрлекләренең (алга таба – Мөлкәт) билгеләнгәнчә файдаланылуын һәм саклануын контрольдә тотуны оештыру буенча эшчәнлеген координацияләү максатларыннан әзерләнгән.

Мөлкәткә түбәндәгеләр керә:

- Татарстан Республикасы казнасын тәшкил итүче;
- Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләренә һәм Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә беркетелгән;
- гражданлык хәле актларына дәүләт теркәве вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнарына бирелгән.

3. Мөлкәтнең тиешенчә файдаланылуын һәм сакланышын контрольдә тоту юридик затларны (алга таба – оешма) тикшерү рәвешендә гамәлгә ашырыла. Тикшерүнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

а) Мөлкәтнең тикшерелгән вакытта документларда теркәлгән халәте белән фактик халәте арасындагы тайпылышларны, аермаларны ачыклау;

б) Мөлкәтнең файдаланылмавын яисә билгеләнмәгәнчә файдаланылуын ачыклау;

в) чара күрү өчен Мөлкәтне иминлек таләпләрен бозып эксплуатацияләү фактларын ачыклау;

г) файдаланылмавы яисә нәтиҗәсез файдаланылуы ачыкланган Мөлкәт белән эш итү турында тәкъдимнәр әзерләү;

д) Мөлкәт белән идарә итү, файдалану һәм эш итү тәртибен җайга салучы законнар бозылу фактларын ачыклау, бозуларны булдырган затларны билгеләү, шулай ук, дәүләт мәнфәгатьләрен саклау максатыннан хокук саклау органнарына, компетенцияләре туры килгән башка органнарга мөрәҗәгать итү.

4. Министрлыкның структур бүлекчәләре белгечләре Мөлкәтне нәтиҗәле файдалану һәм сакланышын контрольдә тоту буенча эшче төркем составында (алга таба – Эшче төркем) түбәндәге Мөлкәткә мөнәсәбәтле тикшерү уздыра:

мөлкәт идарәсе – Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләренә оператив идарә хокукында беркетелгән Мөлкәткә, шулай ук, Татарстан Республикасы казнасын тәшкил иткән Мөлкәткә мөнәсәбәтле;

җир ресурслары идарәсе - Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле;

икътисад бүлеге - Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән Мөлкәткә мөнәсәбәтле.

Исәпләү, мониторинг һәм мәгълүмати хезмәттәшлек идарәсе Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрындагы (алга таба – Реестр) мәгълүматларның тикшерү нәтиҗәсендә алынган мәгълүматларга туры килүен тикшерә.

5. Тикшерү үткәрү максатларында Министрлыкның Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән структур бүлекчәләре мөлкәт идарәсенә ел саен 1 декабрьгә кадәр алдагы елга тикшерү планына тәкъдимнәрен кертәләр.

Мөлкәт идарәсе кергән тәкъдимнәр нигезендә чираттагы елга тикшерүләрнең кварталларга бүленгән җыелма планын төзи, ул Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры (алга таба – Министр) тарафыннан раслана.

6. Оешмаларны тикшерү өч елга бер тапкырдан да ешрак уздырылмый.

7. Тикшерүләр уздыру өчен Министр боерыгы белән эшче төркем төзелә һәм тикшерүләр уздыру срогы билгеләнә.

Эшче төркем составына Министрлыкның структур бүлекчәләре белгечләре, шулай ук, Министрлык ведомствосына караган учреждениеләр хезмәткәрләре кертелә.

Эшче төркем составы өч кешедән дә азрак була алмый.

8. Тикшерү уздыру вакыты 20 көннән дә артык була алмый.

9. Эшче төркем оешмада тикшерү уздырылачагы турында өч көннән дә ким булмаган вакыт эчендә оешма җитәкчесенә яки оешманың вәкаләтле вәкиленә оешмада тикшерү уздыру турында Министрлык боерыгының күчермәсен тапшыру юлы белән хәбәр итә.

10. Тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) актны төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) тикшерү уздыручы орган атамасы;

3) тикшерү уздыру турында Министр боерыгының датасы һәм номеры;

4) тикшерү уздырган затлар турында мәгълүмат (фамилия, исем, әтисенең исеме (булса) һәм вазифасы);

5) оешманың атамасы, тикшерү уздырганда катнашкан оешма җитәкчесе яки вәкаләтле вәкиле турында мәгълүмат (фамилия, исем, әтисенең исеме (булса) һәм вазифасы);

6) тикшерү уздыру датасы, вакыты, дәвамлылыгы һәм урыны;

7) Тәртипнең 11 пункты нигезендә актта чагылган сораулар исемлеге;

8) тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат (сөземтәләр), шул исәптән, ачыкланган тәртип бозулар, аларның характеры һәм күрсәтелгән тәртип бозуларның килеп чыгуына юл куйган затлар турында белешмәләр;

9) ачыкланган тәртип бозуларны бетерү буенча сроклары күрсәтелгән тәкъдимнәр, шулай ук Министрлыкка тәртип бозуларның бетерелүе турында мәгълүмат бирү дә оешманың бурычы булып тора;

10) оешма җитәкчесен яки вәкаләтле вәкилен акт белән таныштыру турында белешмә, шулай ук, тикшерүләрне исәпкә алу журналына үткәрелгән тикшерү турында язылуы яки оешманың андый журналы булмау сәбәпле язу мөмкин түгеллеге турында мәгълүмат;

11) тикшерү уздырган затларның фамилиясе, инициаллары, вазифасы күрсәтелеп, аларның имзасы.

11. Тикшерү уздыру йомгаклары буенча төзелгән актта түбәндәге мәгълүмат чагыла:

- оешманың гамәлгә куелу документлары булуы;
- оешма җитәкчесе белән хезмәт килешүе булуы;
- Мөлкәткә хокукны билгеләгән документларның булуы;
- оешма файдалана торган мөлкәт исемлегенең Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры мәгълүматларына туры килүе;
- оешманың Мөлкәт турында мәгълүматының Реестр мәгълүматына туры килүе;

- оешмага беркетелгән Мөлкәтнең билгеләнгәнчә файдаланылуы һәм сакланышын тикшерү (шул исәптән, тиешле тәртиптә башка затларга тапшырылганда), килешүләр булуы: мөлкәтне файдалану (аренда, түләүсез файдалану һ.б.), коммуналь һәм башка хезмәтләр күрсәтү, Мөлкәт белән эш итүнең канунилыгы (исәптән чыгару, өченче затларга тапшыру тәртибен саклау һ.б.);

- оешмага беркетелгән Мөлкәтне файдалануның икътисади нәтиҗәлелеген билгеләү;

- мобилизацион егәрлек (резервлар), гражданлык оборонасы объектлары һәм мөлкәте, шулай ук, мобилизацион биремнәрнең үтәлеше турында килешүләр (контрактлар) булуы;

- файдаланылмаган Мөлкәтнең булуы;

- сроклары күрсәтелгән төзелеп бетмәгән объектлар булуы һәм төзелешнең тукталу сәбәпләре.

12. Тикшерү акты 3 данәдә төзелә, аның берсе – Министрлыкка, икенчесе – оешмага, өченчесе – Татарстан Республикасының тармак компетенцияле башкарма хакимияте органына (алга таба – тармак органы).

Тикшерү актын эшче төркем әгъзалары имзалый һәм танышу өчен оешма җитәкчесенә яки оешманың вәкаләтле вәкиленә тәкъдим ителә.

13. Җитәкче яки оешманың вәкаләтле вәкиле акт белән танышудан баш тартса яисә аны алу турында расписка бирүдән баш тартса, тикшерү акты оешма адресына заказлы хат белән юллана.

14. Тикшерү актында бәян ителгән сөземтәләр белән килешмәсә, оешма биш көн эчендә Министрлыкка каршы килүен белдергән язмача хат тапшыра.

15. Хокук бозу билгеләре булган фактлар теркәлгән тикшерү акты, мөлкәт идарәсе имза куйганнан соң 14 көн эчендә, чара күрү өчен хокук саклау органнарына юллана.

16. Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турында кодексының 4.3 статьясында каралган тәртип бозулар ачыкланган очракта, Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турында

кодексының 8.1 статьясы нигезендә Министрлык карары белән вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи затлар Министрлык карары белән расланган формада административ хокук бозулар турында беркетмә төзиләр.

Административ хокук бозулар турында беркетмә административ хокук бозулар турында беркетмә төзелгәннән соң өч көн эчендә административ хокук бозулар турында эшләрне карарга вәкаләтле җәмәгать судьясына юллана.

17. Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен тикшерү әлеге Тәртипнең 7, 8, 9, 10, 13, 14, 15 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерү үткәрү йомгаклары буенча төзелгән актта түбәндәге мәгълүматлар чагыла:

1) актны төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) тикшерү уздырган орган атамасы;

3) тикшерү уздыру турында Министр боерыгы датасы һәм номеры;

4) тикшерү уздырган затлар турында белешмә (фамилиясе, исеме, әтисе исеме (булса) һәм вазифа);

5) оешма атамасы, аның җитәкчесе яки тикшерү үткәрелгән вакытта шунда булган вәкаләтле вәкиле турында белешмә (фамилиясе, исеме, әтисе исеме (булса) һәм вазифа);

6) тикшерү уздыру дата, вакыты, дәвамлылыгы һәм урыны;

7) тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат (сөземтәләр), шул исәптән, ачыкланган тәртип бозулар, аларның характеры һәм күрсәтелгән тәртип бозуларның килеп чыгуына юл куйган затлар турында белешмәләр;

8) ачыкланган тәртип бозуларны бетерү буенча сроклары күрсәтелгән тәкъдимнәр, шулай ук Министрлыкка тәртип бозуларның бетерелүе турында мәгълүмат бирү дә оешманың бурычы булып тора;

9) ачыкланган тәртип бозуларны бетерү буенча сроклары күрсәтелгән тәкъдимнәр, шулай ук Министрлыкка тәртип бозуларның бетерелүе турында мәгълүмат бирү дә оешманың бурычы булып тора;

10) тикшерү уздырган затларның фамилиясе, инициаллары, вазифасы күрсәтелеп, аларның имзасы.

18. Оешма законнарга таянып тикшерү актына шикаять белдерергә хокуклы.

19. Эшче төркем квартал саен тикшерү йомгаклары буенча отчет әзерли, ул отчет кварталыннан соң килгән айның утызынчы көненнән дә калмыйча, тикшерүләр уздыру турында боерык нигезендә әлеге тикшерүләрне үз карамагында торкан министр урынбасарына һәм тармак органына юллана.

20. Оешма ачыкланган тәртип бозуларны бетерү чаралары күрмәгән очракта, мөлкәт идарәсе тармак органына оешма җитәкчесен законнар нигезендә җаваплылыкка тарту буенча тәкъдимнәр юллый.